ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.10.2022 ел Баулы шәһәре № 220

2023 елга балаларны йөртү өчен билгеләнгән махсус автобуслар белән Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакының нормативларын раслау турында

«Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы түбәндәгеләрне расларга:

2023 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативларын (1 нче кушымта);

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне (2 нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакы нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
башкарма комитеты вазифаларын
башкаручы – җитәкченең беренче
урынбасары

И.И. Хөснуллина

1 нче кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның 26
октябрендәге 220 номерлы карары
белән расланган

2023 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативларын

| Автотранспорт моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер километрны узу ставкасы, елына сум |
| КАВЗ | 613418 | 20,86 |
| ПАЗ | 613675 | 21,02 |
| ГАЗ «Газель» | 593227 | 13,56 |
| УАЗ | 592774 | 11,87 |
| FIAT | 596122 | 9,98 |
| Peugeot Boxer | 601272 | 9,61 |
| Ford Transit | 601529 | 13,74 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 615632 | 18,67 |

2 нче кушымта

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның 26
октябрендәге 220 номерлы карары
белән расланган

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең, автотранспорт чаралары санының һәм хисап чорына автотранспорт чараларының фактта йөрүенең нормативы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең ы нормативлары ел саен Баулы муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактта йөрүе турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча, автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының фактик йөгереше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

1.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

где:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактик йөгереше, километр

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясенең нормасы бер километргa, сум

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүнең оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына ставкасы, сум;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар саны.